СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

29.11.2023 Әгерҗе ш. № 31-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 35-2 номерлы карарына протестын карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 15 октябрендәге 35-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының финанс-бюджет мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе
Муниципаль берәмлек башлыгы Л.Ф. Нургаянов